ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 25 статьясына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2025 елның 25 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2012 елның 22 декабрендәге 87-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 25 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 12 (I өлеш); 2013, № 12 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 3, № 10 (I өлеш); 2016, № 3, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 25 (I өлеш); 2017, № 52 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2019, № 28 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 34 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 48 (I өлеш), № 86 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2024, № 45 (I өлеш), № 79 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 өлештә:

а) 1 пунктның «в» пунктчасында «, шулай ук идентификацияләү мөмкин булмаган һәм мәҗбүри медицина иминияте буенча иминләштерелмәгән гражданнарга мәҗбүри медицина иминиятенең база программасына кертелгән авырулар булганда һәм халәтләрдә ашыгыч һәм кичектергесез рәвешләрдә медицина ярдәме күрсәтү буенча» сүзләрен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле $6^3$ пункт өстәргә:

«$6^3$) Татарстан Республикасы законнары нигезендә гражданнарның аерым категорияләренә ишетү органнарын протезлау буенча хезмәтләр күрсәтү;»;

2) 2 өлештә:

а) дүртенче абзацта «һәм мәҗбүри медицина иминияте өлкәсендә эшчәнлек башкармый торган» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) тугызынчы абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

в) унынчы абзацта «һәм ишетү органнарын протезлау» сүзләрен төшереп калдырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2025 ел, 10 октябрь
№ 69-ТРЗ